**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.07.2017 Балык Бистәсе штп. № 164пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата таләпләрне раслау турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу системасын камилләштерү максатларында һәм «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 4 өлешенең 1 пункты нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләрне раслау турында " 2015 елның 18 маендагы №476 карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата таләпләрне (алга таба-таләпләр) расларга

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Муниципаль заказ хезмәте» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә таләпләрне «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Муниципаль заказчы хезмәте” муниципаль казна учреждениесенә йөкләргә.

Житәкче Р. Х. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2017 елның 18 июлендәге 164
пи номерлы карары белән
расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата таләпләр**

1. "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында «2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата гомуми таләпләрне раслау турында» (алга таба – 476 номерлы карар) 2015 елның 18 маендагы 476 номерлы карары нигезендә эшләнгән әлеге документ түбәндәге хокукый актларны эшләү һәм кабул итү тәртибенә, эчтәлегенә, үтәүне тәэмин итүгә карата таләпләр билгели (алга таба-таләпләр):

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты, раслаучы:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының ведомство буйсынуындагы муниципаль казна учреждениеләрен дә кертеп, муниципаль органнар функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен ;

Муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль бюджет учреждениеләре һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре тарафыннан товарларның аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләренә)карата сатып алына торган таләпләрне билгеләү кагыйдәләрен;

б) муниципаль органнарны раслый торган:

муниципаль органнар функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнар (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының ведомство буйсынуындагы муниципаль казна учреждениеләрен дә кертеп);

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль бюджет учреждениеләре һәм муниципаль унитар предприятиеләре тарафыннан товарларның аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләренә) алар тарафыннан сатып алына торган таләпләр.

2.Әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актлар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары проектлары рәвешендә эшләнә.

Әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актлар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты, аңа караган муниципаль казна, муниципаль бюджет учреждениеләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары проектлары рәвешендә эшләнә.

Әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актлар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы Аппараты өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы карарлары проектлары рәвешендә эшләнә.

Әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актлар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының башка җирле үзидарә органнары өчен тиешле муниципаль органнарның вазыйфаи затлары боерыклары (күрсәтмәләре) проектлары рәвешендә эшләнә.

3.Әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында һәм «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән хокукый актлар проектлары буенчаТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Иҗтимагый советы утырышларында мәҗбүри рәвештә фикер алышынырга тиеш.

4.Әлеге таләпләрнең 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын җәмәгать контроле максатларында фикер алышуны үткәрү өчен, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында хокукый актларны эшләү һәм кабул итү тәртибенә гомуми таләпләрне раслау турында» (алга таба - гомуми таләпләр, иҗтимагый контроль максатларында фикер алышу) 2015 елның 18 маендагы 476 номерлы карары белән расланган сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында хокукый актларны эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләрнең 6 пункты нигезендә,, муниципаль органнар күрсәтелгән хокукый актлар проектларын һәм аларга аңлатма язмаларын әлеге таләпләрнең 5 пунктында билгеләнгән срокка сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында әзерләнгән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштыралар.

5.Иҗтимагый контроль максатларында фикер алышуны үткәрү вакыты муниципаль органнар тарафыннан билгеләнә һәм әлеге таләпләрнең 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштырганнан соң 7 календарь көненнән дә ким булмаска тиеш.

6.Муниципаль органнар, әлеге таләпләрнең 5 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, күрсәтелгән органнар тарафыннан

билгеләнгән вакытта электрон яисә язма рәвештә кергән иҗтимагый берләшмәләрнең, юридик һәм физик затларның тәкъдимнәрен карый.

7. Муниципаль органнар иҗтимагый берләшмәләр, юридик һәм физик затлар тәкъдимнәрен караган көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге тәкъдимнәрне һәм җаваплар сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында билгеләнгән тәртиптә урнаштыралар.

8.Иҗтимагый контроль максатларында фикер алышу нәтиҗәләре буенча муниципаль органнар, кирәк булганда, иҗтимагый берләшмәләр, юридик һәм физик затлар тәкъдимнәрен исәпкә алып, әлеге таләпләрнең 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Иҗтимагый советы утырышларында әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында һәм «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын (алга таба-хокукый актлар проектларын) карап тикшерү турында Карар кабул итәләр (алга таба - Иҗтимагый совет) әлеге таләпләрнең 3 пункты һәм 3 пункты нигезендә эшли.

9.Әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында һәм «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын карау нәтиҗәләре буенча иҗтимагый совет түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) хокукый акт проектын эшләп бетерү зарурлыгы турында;

б) хокукый актны кабул итү мөмкинлеге турында.

10.Иҗтимагый советтан хокукый акт проектын эшләп бетерү кирәклеге турында бәяләмә алынган очракта, муниципаль органнар әлеге проектны, Иҗтимагый совет кисәтүләрен исәпкә алып, өч эш көненнән дә соңга калмыйча эшләп бетерәләр һәм аны кабат Иҗтимагый советка җибәрәләр.

11. Иҗтимагый советтан уңай бәяләмә алган очракта, муниципаль орган хокукый акт проектын раслый.

12.Иҗтимагый совет тарафыннан кабул ителгән карар, тиешле карар кабул ителгән көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, барлык әгъзалары кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул муниципаль органнар тарафыннан Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

13. Әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында каралган хокукый актлар елына кимендә бер тапкыр карала. Күрсәтелгән хокукый актларны яңадан карау Иҗтимагый совет утырышларында гамәлгә ашырыла, анда түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) хокукый актка аны кабул итү өчен билгеләнгән тәртиптә үзгәрешләр кертү кирәклеге турында;

б) хокукый актка үзгәрешләр кертү зарурлыгы булмау турында.

14.Әлеге таләпләрнең 9 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән карар кабул ителгән очракта, муниципаль органнар әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында һәм «б» пунктчасының

өченче абзацында күрсәтелгән хокукый актларны Иҗтимагый совет кабул иткән карарлар нигезендә эшләп бетергәннән соң раслыйлар.

15.Муниципаль органнар әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актлар кабул ителгәннән соң 7 эш көне эчендә әлеге хокукый актларны билгеләнгән тәртиптә сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыралар.

16. Әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актларга үзгәрешләр кертү аларны кабул итү өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

17.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль органнар, муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль бюджет учреждениеләре һәм муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан сатып алына торган товарларның аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләренә) карата таләпләрне билгеләү кагыйдәләрен раслый торган карары гомуми таләпләрнең 4 пунктында каралган мәгълүматны үз эченә алырга тиеш.

18.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль органнар, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен раслый торган карары гомуми таләпләрнең 5 пунктында каралган мәгълүматны үз эченә алырга тиеш.

19.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль органнары, муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль бюджет учреждениеләре һәм муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан сатып алына торган товарларның аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләре) таләпләрне раслаучы муниципаль хокукый актлар һәм (яки) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны заказчылар тарафыннан үтәүне тикшерү, сатып алулар өлкәсендә контроль һәм мониторинг барышында муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.